РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.03.2022 № 388

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү муниципаль оешмаларында исәп-хисап (расчёт) тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 июнендәге 471 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы коллегиясенең киңәйтелгән утырышы эш нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның күрсәтмәләрен үтәү йөзеннән, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү муниципаль оешмаларында исәп-хисап (расчёт) тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 июнендәге 471 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 нче кушымтада 1.3 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләр, шул исәптән көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге студентлар өчен ата-аналар түләве күләме ата-аналар түләвенең 50 процентын тәшкил итә.»

1.2. 3 нче кушымтада 1.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Ата-аналарның берсе эчке эшләр министрлыгы хезмәткәре булган гаиләләр өчен ата-аналар түләвенең күләме 50 процентка кими. Әлеге ташлама Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге тарафыннан, хезмәткәрләр реестры нигезендә, Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенә һәр ай саен, агымдагы айның 10 числосына кадәр юлланыла.»

1.3. 3 нче кушымтада 1.4 пунктын түбәндәге эчтәлекле 1.4.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«1.4.1. Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге хезмәткәрләреннән тыш, ата-ана түләвеннән азат итү яки аны 50 процент күләмендә түләү хокукын раслау өчен - ата-аналар (законлы вәкилләр) түбәндәге документларны тапшыралар:

- белем бирү муниципаль оешмасы җитәкчесе исеменә ташламалар бирү турында язмача рәвештә гариза;
- гаилә составы турында белешмә;

Югарыда күрсәтелгәннәрдән тыш, гражданнарның аерым категорияләре өстәмә рәвештә түбәндәге документларны тапшыра:

- опекуннар, тәрбиягә алган ата-аналар - алмаштыручы ата-ана статусын раслаучы хокукый акт күчермәсе;
- инвалид баланың ата-анасы - инвалидлык һәм медицина бәяләмәсе турында белешмә күчермәләре;
- өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче ата-аналар (законлы вәкилләр) - күпбалалы гаилә турындагы таныклык күчермәсе;
- мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче, ике бала тәрбияләүче, 1 яки 2 төркемдәге инвалид ата-ана, инвалидлык турында белешмә күчермәсе;
- мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче, бер бала тәрбияләүче, 1 яки 2 төркемдәге инвалид ата-ана инвалидлык турында белешмә күчермәсе һәм җан башына керемнең Татарстан Республикасы буенча минималь яшәү минимумыннан түбән булуын раслаучы документ: мөрәҗәгать иткән айдан алдагы 6 эчендә, балага айлык пособие билгеләү турында белешмә, әлеге белешмәнең гамәлдә булу вакытын күрсәтеп, йә гаиләнең барлык әгъзаларының керемнәре турында документлар тапшыра.

Әлеге ташламаларны алу хокукы ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) документлар белән гариза тапшырган айдан, аларны агымдагы айның 20 числосына кадәр тапшырган очракта, гамәлгә ашырыла.

Гаризаны агымдагы айның 20 числосыннан соң тапшырганда ташлама киләсе айдан гамәлгә ашырыла.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) тапшырган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

Ташламалар бирү турында гариза һәм аңа теркәлә торган документлар тапшырылган көненнән алып 3 эш эчендә мәктәпкәчә белем бирү муниципаль оешмасы җитәкчесе тарафыннан карала, карау нәтиҗәләре буенча ташламалар бирү яисә бирүдән баш тарту турында мәктәпкәчә белем бирү муниципаль оешмасы җитәкчесе тарафыннан карар кабул ителә.

Әлеге Тәртипнең 1.3 - 1.4 пунктларында каралган ташламалар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- әлеге Тәртипнең 1.4.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган исемлеген тапшыру;
- тәкъдим ителгән документлардагы белешмәләрнең дөрес булмавы.

Ата-аналарга (законлы вәкилләргә) кабул ителгән карар, аны кабул иткән көннән алып 3 эш көне эчендә хәбәр ителә.

Берничә нигез буенча ташлама алу хокукына ия ата-аналарга (законлы

вәкилләренә) ташлама аларның теләге буенча нигезләрнең берсенә таянып билгеләнә».

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү муниципаль оешмаларында исәп-хисап (расчёт) тәртибен раслау турында» Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 3 февралендәге 104 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 1361 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA
Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович
Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Л.Ф. Нургаянов